БОЛЬШЕМЕНГЕРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422008, Республика Татарстан, Атнинский район, с.Большой Менгер, ул.Советская, д.8, т.3-46-25

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентября 2024 г. № 9

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 28.02.2017 ел № 5 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибе”нә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2020 N 98-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 01.05.2019 № 71-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2024 елның 28 июнендәге «02-08-02-2024/Прдп281-24» протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районының Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 5 номерлы карары (21.07.2021, № 14, 03.04.2023 №6 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Мәңгәр авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 10 пунктын төшереп калдырырга;

1.2. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

“13. План-графикка түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алуларның идентификация кодлары;

2) объектның исеме һәм (яисә) сатып алу объектларының атамалары;

3) сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү күләме;

4) планлаштырыла торган сатып алуларны гамәлгә ашыруның сроклары (вакыты);

5) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә товарны, эшне яисә хезмәтләрне сатып алулар турында иҗтимагый фикер алышу турында мәгълүмат;

6) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында каралган тәртип белән билгеләнгән башка мәгълүмат.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Филатова Ф.Ф.